**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
**15 нче ноябрь, 2021 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№12-01**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле муниципаль контроль төрләре исемлеге турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131- ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгын тәэмин итү максатларында, Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм муниципаль контроль төрләре исемлеген расларга (1 нче кушымта).
2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына Актаныш муниципаль районы территориясендә аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле муниципаль контроль төрләре һәм башкарма комитет органнары исемлеген алып баруны йөкләргә.
3. Актаныш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнары һәм муниципаль контроль төрләре исемлеге турында» 2019 елның 16 декабрендәге 43-08 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында http://aktanysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә игълан итәргә.

Муниципаль район Башлыгы, Совет Рәисе Э.Н.Фәттахов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
ОГРН 1051667009734
ИНН 1604006751

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Советы карарына
15 нче ноябрь, 2021 ел №12-01
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле муниципаль контроль төрләре исемлеге

| т/б | Муниципаль контроль төре | Муниципаль контроль төрен гамәлгә ашыруны регламентлаучы норматив хокукый актлар (конкрет нигезләмә, статья, пункт, абзацларны күрсәтеп, реквизитларны да кертеп) | Муниципаль контроль төрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар (структур бүлекчәләр) |
|---|---|---|---|
| 1. | Муниципаль торак контроле | Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары» | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының торак секторы |
| 2. | Муниципаль җир контроле | Россия Федерациясе Җир кодексының 72 ст., «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 | Актаныш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 ст. 1 бүлегенең 26 пунктчасы | |
| 3. | Төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль норматив хокукый актларның үтәлешенә муниципаль контроль | Татарстан Республикасы Экология кодексы; «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |